**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(V чакырылыш)**

# КАРАР

**җиденче утырыш**

**3 апрель 2026 ел** **№ 24** **Теләче ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2016 елның 28 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы федераль законнар, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 февралендә 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советының 2016 елның 28 декабрендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 3 өлешендәге «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3 бүлекнең 8.1 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы)» сүзләрен «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә өлкәсендәге законнары» белән алыштырырга;

1.3. 4 бүлекнең 3 өлешенең 4 пунктында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 5 бүлектә:

а) 3 өлешнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон белән билгеләнгән, керем турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар;»;

б) 7 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы белән» сүзләрен «Гаммәви хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.5. 15 бүлек 6 пункт 2 өлештә «, муниципаль берәмлек Сайлау комиссиесе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6. 19 бүлекнең 9 өлешендә «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.7. 27.1 бүлектә:

а) 1 өлешне түбәндәгечә бәян итәргә:

1. Муниципаль хезмәт урынын биләргә дәгъва кылучы гражданин, муниципаль хезмәткәр эш бирүче вәкиленә (эш бирүчегә) 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны, әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда, тапшыра. Күрсәтелгән мәгълүматлар "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Муниципаль хезмәт урынын биләгән муниципаль хезмәткәр, тиешле исемлеккә кертелгән, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматларны, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан шундый мәгълүматларны тапшыру тәртибе һәм формасы буенча тапшырырга бурычлы.»;

в) 4 өлештә:

- «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мәлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «әлеге статья нигезендә» сүзләрен «әлеге бүлек нигезендә» сүзләренә алыштырырга;

г) 5 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлек нигезендә тәкъдим ителә торган мәгълүматлар» сүзләренә алыштырырга;

д) 6 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» дигән сүзләрне «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлек нигезендә тәкъдим ителә торган мәгълүматлар» дигән сүзләргә алыштырырга;

е) 7 пунктта «үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар

һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматлар» сүзләре белән алыштырырга»,»;

ж) түбәндәге эчтәлекле 7.1 өлеш белән тулыландырырга:

«7.1. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге бүлекнең 7 өлешендә күрсәтелгән белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

1.8. 28 бүлектә:

а) 1.2 өлештә:

- «а» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «б» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1.4 өлешне түбәндәгечә бәян итәргә:

«1.4. әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль хезмәт вазыйфасын үзе биләгән йә турыдан-туры аңа буйсынган яисә контрольдә тотылган җирле үзидарә органында ышанычлы яисә өченче затлар эшләре буенча вәкил булырга

в) 1.6 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 1.9 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 29 бүлекнең 4 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

«4. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатында, җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесенең урынбасары, тиешле вазыйфаны биләгән чорда, әлеге җирле үзидарә органының сайлаулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен вәкиллек итә алмый.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Теләче авыл җирлеге башлыгы — А.Г. Фатхуллин

Совет Тюлячинского сельского поселения
Теләче авыл җирлеге советы